ГЛАВА СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская,
д.12, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Иске Каразирек авылы, Совет
урамы, 12 йорт,
423965

Тел./факс: (85593) 4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 2 25 сентябрь 2020 ел

2020 елның 1 июнендәге Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгының 1 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы, 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ санлы Федераль законнар, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

карар бирәм:

1.2020 елның 1 июнендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгының 1 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 бүлектә «ел саен» сүзен «һәрдаим» (әмма елына бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә) дип алмаштырырга;

- 5 һәм 8 бүлекләрдә «хисап чорыннан соң килүче» сүзләрен «киләсе хисап елы» дигән сүзләргә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы: Р. Р. Вэлиев